# МИТЧЕЛЛ ЛАРКИН – 200 МЕТРГА АРКАДА ЙӨЗҮ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНЫ

07.08.2015, 17:57
СПОРТ

**Бу минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында икенче финал йөзеше төгәлләнде. 200 метрга аркада йөзү ярышында дөньяның иң җитез 8 йөзүчесе ярышты.**

Алтын медальгә әлеге дистанцияне 1:53.58 нәтиҗәсе белән йөзеп узган австралияле Митчелл Ларкин ия булды. Икенче урында – Польша спортчысы Радослав Кавецки, ул күрсәткән вакыт - 1:54.55. Призлы өчлекне россияле Евгений Рылов япты, аның вакыт күрсәткече - 1:54.60.

ДЧ-2015. Йөзү

Ир-атлар. Аркада, 200 м.

1. Митчелл Ларкин (Австралия) - 1:53.58

2. Радослав Кавецки (Польша) - 1:54.55

3. Евгений Рылов (Россия) - 1:54.60

7 август. Казан. “Казан Арена”

Су спорт төрләре буенча 16 нчы дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА